**9. Нәүрүз**

Аккош кебек күпереп, Идел буйлап
Нәүруз килә - язның чибәре.
Бәгырьләргә кагылып үтә җыры,
Хуш ис бөрки назлы җилләре.
Кушымта: Кояш үртәп йөри, шаян кызый,
Ай ояла, кача, югала.
Йолдызлардан такыя үреп бирәм-
Кил Нәүрүз, кил Нәүрүз минем дөньяма!
Март кояшы Идел бозын ашый,
Ярдан атлый Нәүрүз чибәре.
Күлмәгеннән тамып -тамып кала
Яз аеның матур гөлләре.
Кушымта.
Кочып ала аны мәшһүр Казан!
Сагынгандыр нечкә билкәен...
Кавышыр чагы җиткән Казан белән,
Хуш киләсең – Нәүрүз, чибәрем!